ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

28 ноябрь 2023 ел Кәрәкәшле ав. № 35

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карарын үз көчен
югалткан дип тану турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2007 елның 01 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетының вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмәне раслау хакында»гы 11 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев